**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

## Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе секретариаты турында нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында» 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы Указы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе секретариаты турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе секретариаты турында нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 20 декабрендәге ПУ-1253 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым актлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 17 декабрендәге ПУ-889 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 18 пункты.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 30 май
№ 361

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның « 30 » маендагы
361 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе секретариаты турында нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе секретариаты (алга таба шулай ук – секретариат) Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең структур бүлекчәсе булып тора.

2. Секретариат Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе эшчәнлеген мәгълүмати-аналитик, документлар белән, оештыру, техник һәм башка яктан тәэмин итү максатларында төзелде.

3. Секретариат Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан төзелә, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә буйсына.

4. Секретариат үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Рәисе указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында нигезләмәгә, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе боерыкларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

5. Секретариат турында нигезләмә Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

II. Секретариатның төп бурычлары

6. Секретариатның төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе эшчәнлеген мәгълүмати-аналитик, документлар белән, оештыру, техник һәм башка яктан тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенең Татарстан Республикасы дәүләт органнары, федераль дәүләт органнары һәм аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм граждан җәмгыяте институтлары белән үзара эшчәнлеген тәэмин итү.

## III. Секретариатның төп функцияләре

7. Секретариатның төп функцияләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе кушуы буенча кирәкле булган мәгълүмати, аналитик, белешмә һәм башка материалларны, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе докладларын һәм чыгышларын әзерләүне тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең структур бүлекчәләре белән бергәләп, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе докладлары һәм чыгышлары, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе уздыра торган яисә аның катнашында уза торган киңәшмәләр һәм башка чаралар өчен мәгълүмати, аналитик, белешмә һәм башка материаллар әзерләүдә катнашу;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе кушуы буенча Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе боерыкларының һәм йөкләмәләренең, шул исәптән Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан расланган киңәшмәләр беркетмәләрендәге йөкләмәләрнең үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе уздырган сөйләшүләрне, аның очрашуларын, командировкаларын, эш сәфәрләрен планлаштыруны, координацияләүне, әзерләүне һәм уздыруны тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе уздырган киңәшмәләрне оештыру, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе кушуы буенча, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе структур бүлекчәләре катнашында, әлеге киңәшмәләрдә кабул ителгән карарларны рәсмиләштерү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе структур бүлекчәләре белән бергәләп, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе уздыра торган башка чараларны оештыру һәм беркетмә ягыннан тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенең Россия Федерациясе субъектларына һәм чит илләргә визитларын әзерләүдә катнашу;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе кушуы буенча Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе структур бүлекчәләре белән бергәләп Татарстан Республикасы Рәисе указлары һәм боерыклары проектларын, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе боерыклары һәм башка документлар проектларын әзерләү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе кушуы буенча Татарстан Республикасы дәүләт органнары, федераль дәүләт органнары һәм аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар җитәкчеләре, шулай ук граждан җәмгыяте институтлары белән оператив рәвештә үзара эшчәнлекне тәэмин итү;

оператив мәгълүматны кабул итүне тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе кушуы буенча Татарстан Республикасы Рәисенең Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү идарәсе белән берлектә гражданнарны кабул итүне оештыру, гражданнарны кабул итү йомгаклары буенча кабул ителгән карарлар үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә әзерләнгән Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенең карар кабул итүе таләп ителгән йөкләмәләр проектларын һәм башка материалларны Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә вакытында бирүне тәэмин итү.

Секретариат Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе кушуы буенча шулай ук башка функцияләрне дә башкара.

## IV. Секретариатның хокуклары

8. Үз бурычларын һәм функцияләрен тормышка ашыру өчен секретариат түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе структур бүлекчәләреннән, Татарстан Республикасы дәүләт органнарыннан, федераль дәүләт органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр һәм вазыйфаи затлардан билгеләнгән тәртиптә кирәкле материалларны соратып алырга;

Татарстан Республикасы Рәисе указлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе боерыклары һәм башка документлар проектларын эшләүдә катнашырга;

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмати системаларындагы мәгълүматлардан файдаланырга;

билгеләнгән тәртиптә дәүләт элемтә һәм коммуникация системаларыннан файдаланырга;

## V. Секретариатның хезмәттәшлек итү даирәсе

9. Секретариат үзенә йөкләнгән функцияләрне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе структур бүлекчәләре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары, федераль дәүләт органнары һәм аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм вазыйфаи затлар белән хезмәттәшлек итә.

## VI. Җаваплылык

10. Секретариат хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан расланган вазыйфаи регламентлар нигезендә аларга йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җаваплы була.

## VII. Секретариат эшчәнлеген оештыру

11. Секретариатның структурасы һәм штат саны Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

12. Секретариат эшчәнлегенә Татарстан Республикасы Рәисе боерыгы нигезендә вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе секретариаты җитәкчесе (алга таба – секретариат җитәкчесе) җитәкчелек итә.

13. Секретариат җитәкчесе:

секретариатка йөкләнгән бурычларның һәм функцияләрнең үтәлешен тәэмин итә;

секретариат компетенциясе чикләрендә карарлар кабул итә һәм хезмәт документациясенә кул куя;

Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе уздырган киңәшмәләрдә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларында катнаша;

билгеләнгән тәртиптә секретариат хезмәткәрләрен бүләкләү һәм аларны дисциплинар җәзага тарту турындагы тәкъдимнәр бирә;

секретариатка йөкләнгән бурычларның һәм функцияләрнең вакытында һәм сыйфатлы үтәлүе, хезмәт дисциплинасының торышы өчен җаваплы була.

14. Секретариат хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә.

---